# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих авылында

2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 25 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих авылында гражданнар җыены нигезендә

Карары:

1. 2025 елда авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегендә көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш (СВО катнашучылары).

2. Жыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен роторлы кар чистарткыч сатып алу);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Салих авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту).

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (http://bavly.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче___________ И. Н. Хәйруллин